ГОСУДАРСТВЕННАЯ
ЖИЛИЩНАЯ ИНСПЕКЦИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Б.Красная, 15/9, г.Казань, 420111

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫ ДӘҮЛӘТ
ТОРАК ИНСПЕКЦИЯСЕ
Б.Красная ур. 15/9, Казан шәһәре, 420111

тел/факс. 236-91-44. E-mail: tatgi@tatar.ru, сайт: www.gji.tatarstan.ru

№ 31

**П Р И К А З** **Б О Е Р Ы К**

«24» 01 2019ел.

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2017 елның 30 октябрендәге 326 номерлы боерыгы белән расланган Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең норматив хокукый актларын Россия Федерациясе законнарына туры китерү максатларында боерык бирәм:

1. Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2017 елның 30 октябрендәге 326 номерлы боерыгы (Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясенең 2018 елның 09 апрелендәге 137 номерлы, 2018 елның 23 июлендәге 275 номерлы боерыклары нигезендә кертелгән үзгәрешләре белән) белән расланган Татарстан Республикасында Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына (алга таба – Регламент) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1 бүлектә:

1.2 пунктта:

түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт карары» дәүләт мәгълүмат системасына тиешле мәгълүматны кертү билгеләнгән тәртиптә Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Тиешле мәгълүматны «Татарстан Республикасының йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертү билгеләнгән тәртиптә Инспекциянең вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан гамәлгә ашырыла.»;

1.3 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.3. Дәүләт функциясе түбәндәгеләргә нигезләнеп гамәлгә ашырыла:

Россия Федерациясе Конституциясе;

Россия Федерациясе Гражданлык кодексы (алга таба – РФ ГК);

Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексы (алга таба – РФ КоАП);

Россия Федерациясе Җир кодексы (алга таба – РФ ҖК);

«Кулланучыларның хокукларын яклау турында» 1992 елның 7 февралендәге 2300-1 номерлы Россия Федерациясе Законы (алга таба – 2300-1 номерлы федераль закон) (Российская газета, 1996, 16 гыйнвар, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге 181-ФЗ номерлы федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1995, № 48, 4563 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе субъектларының закон чыгару (вәкиллекле) һәм дәүләт хакимияте башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 1999, № 42, 5005 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Техник җайга салу турында» 2002 елның 27 декабрендәге 184-ФЗ номерлы федераль закон (Российская газета, 2002, 31 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы федераль закон (Российская газета, 2003, 8 октябрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясе гражданнарының мөрәҗәгатьләрен карау тәртибе турында» 2006 елның 2 маендагы 59-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 59-ФЗ номерлы федераль закон)(Российская газета, 2006, 11 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 2008 елның 26 декабрендәге 294-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 294-ФЗ номерлы федераль закон) (Российская газета, 2008, 30 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Энергия саклау турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2009 елның 23 ноябрендәге 261-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 261-ФЗ номерлы федераль закон) (Российская газета, 2009, 27 ноябрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Биналарның һәм корылмаларның ышанычлылыгы турында техник регламент» 2009 елның 30 декабрендәге 384-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 384-ФЗ номерлы федераль закон) (Российская газета, 2009, 31 декабрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Россия Федерациясендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре турында» 2014 елның 29 декабрендәге 473-ФЗ номерлы федераль закон (алга таба – 473-ФЗ номерлы федераль закон) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2014, 29 декабрь, бастырып чыгару номеры: 0001201412290024, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Торак урыннарыннан файдалану кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 21 гыйнварындагы 25 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 25 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары

җыентыгы, 2006, № 5, 546 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Бүлмә урынын торак урын, торак урынны яшәү өчен яраксыз һәм күпфатирлы йортны аварияле һәм сүтелергә яисә үзгәртеп корылырга тиеш дип тану турында нигезләмә раслау турында» 2006 елның 28 гыйнварындагы 47 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 47 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 6, 702 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Коммуналь хезмәтләрдән файдалану нормативларын һәм күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту максатларында коммуналь ресурслардан файдалану нормативларын билгеләү һәм ачыклау кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 23 маендагы 306 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 306 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 22, 2338 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта гомуми милекне карап тоту кагыйдәләрен һәм күпфатирлы йортта уртак мөлкәт белән эш итү, аны карап тоту һәм ремонтлау буенча тиешсез сыйфатта һәм (яисә) билгеләнгән озынлыгын артып китүче өзеклекләр белән хезмәтләр күрсәтелгән һәм эшләр башкарылган очракта торак урынны карап тоту өчен түләү күләмен үзгәрү кагыйдәләрен раслау турында» 2006 елның 13 августындагы 491 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 491 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2006, № 34, 3680 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Гражданнарның коммуналь-көнкүреш ихтыяҗларын тәэмин итү өчен газ китертү тәртибе турында» 2008 елның 21 июлендәге 549 номерлы карары (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2008, № 30, 3635 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары һәм муниципаль контроль органнары тарафыннан юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр үткәрүнең еллык планнарын әзерләү кагыйдәләрен раслау турында» 2010 елның 30 июнендәге 489 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 489 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2010, № 28, 3706 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмалар тарафыннан мәгълүмат ачу стандартын раслау турында» 2010 елның 23 сентябрендәге 731 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 731 номерлы карары белән расланган стандарт), (Российская газета, 2010, 1 октябрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерация Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне тиешенчә карап тотуны тәэмин итү өчен кирәкле хезмәтләрнең һәм эшләрнең минималь исемлеге һәм аларны күрсәтү һәм башкару тәртибе турында» 2013 елның 3 апрелендәге 290 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 290 номерлы карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2013, 12 апрель, бастырып чыгару номеры: 0001201304120004, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Энергия саклау турында һәм энергетика нәтиҗәлелеген арттыру турында законнардагы таләпләрнең үтәлүенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыру кагыйдәләрен раслау турында һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2011 елның 25 апрелендәге 318 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 318

номерлы карары) (Российская газета, 2011, 29 апрель, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында» 2011 елның 6 маендагы 354 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 354 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2011, № 22, 3168 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Йорт эче һәм фатир эче газ җайланмасыннан файдаланганда һәм аны карап тотканда куркынычсызлык тәэмин итү чаралары турында» 2013 елның 14 маендагы 410 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 410 номерлы карары)(Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2013, 24 май, басылып чыгу номеры: 0001201305240001, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшчәнлекне гамәлгә ашыру тәртибе турында» 2013 елның 15 маендагы 416 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 416 номерлы карары)(Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2013, 22 май, басылып чыгу номеры: 0001201305220001, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт торак күзәтчелеге турында» 2013 елның 11 июнендәге 493 номерлы карары (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2013, 17 июнь, басылып чыгу номеры: 0001201306170023, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрнең бердәм реестрын формалаштыру һәм алып бару кагыйдәләре турында» 2015 елның 28 апрелендәге 415 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 415 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 19, 2825 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контролен (күзәтчелеген), муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләре резидентларына карата уздырыла торган уртак планлы тикшерүләр турында» 2015 елның 22 октябрендәге 1132 номерлы карары (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 1132 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2015, № 44, 6127 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләр оештырганда һәм үткәргәндә ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан документларга һәм (яисә) мәгълүматларга, шул исәптән электрон рәвештә, шушы документлар һәм (яисә) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына яисә дәүләт органнарына яисә җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмаларга гарызнамәләр җибәрү һәм аларны түләүсез нигездә алу турында» 2016 елның 18 апрелендәге 323 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 323 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016 № 17, 2418 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Күпфатирлы йортта торак урыннарны һәм уртак мөлкәтне инвалидларның ихтыяҗларын исәпкә алып яраклаштыру чаралары турында» 2016 елның 9 июлендәге 649 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 649 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 30, 4914 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Дәүләт контроленең (күзәтчелегенең) аерым

төрләрен оештырганда куркыныч-юнәлешле якын килүне куллану һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 17 августындагы 806 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 806 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 35, 5326 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнары һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарындагы вазыйфаи затлар эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарындагы вазыйфаи затларга тикшерүләр уздыруның еллык планнары проектларын әзерләү, шулай ук Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарына һәм Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимияте органнарындагы вазыйфаи затларга планнан тыш тикшерүләрне килештерү турында» 2016 елның 31 октябрендәге 1106 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 1106 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 45, 6270 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Зарури таләпләрне бозуның ярамаганлыгы турында кисәтүләр төзү һәм җибәрү, юридик зат, шәхси эшкуар тарафыннан мондый кисәтүләргә ризасызлыклар бирү һәм аларны карап тикшерү, мондый кисәтүне үтәү турында хәбәр итү кагыйдәләрен раслау турында» 2017 елның 10 февралендәге 166 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 166 номерлы карары) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2017, № 8, 1239 ст.);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт карары» дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2018 елның 21 апрелендәге 482 номерлы карары (алга таба – РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 25 апрель, бастырып чыгару номеры: 001201804250009, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Тикшерүләрне оештырганда һәм үткәргәндә дәүләт контроле (күзәтчелеге) органнары, муниципаль контроль органнары тарафыннан ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында шушы документлар һәм (яки) мәгълүматлар белән эш итүче бүтән дәүләт органнарыннан, җирле үзидарә органнарыннан яисә дәүләт органнарына яки җирле үзидарә органнарына буйсынучы оешмалардан сорала һәм алына торган документлар һәм (яки) мәгълүматлар исемлеген раслау турында» 2016 елның 19 апрелендәге 724-р номерлы боерыгы (алга таба – Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 724-р номерлы боерыгы) (Россия Федерациясе законнары җыентыгы, 2016, № 18, 2647 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төзелеш һәм торак-коммуналь комплекс буенча дәүләт комитетының «Торак фондын техник эксплуатацияләү кагыйдәләрен һәм нормаларын раслау турында» 2003 елның 27 сентябрендәге 170 номерлы карары (алга таба – ПиН) (Российская газета, 2003, 23 октябрь);

Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының «2008 елның 26 декабрендәге «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» 294-ФЗ номерлы Федераль законны тормышка ашыру хакында» 2009 елның 27 мартындагы 93 номерлы боерыгы (алга таба – РФ Генпрокуратурасының 93 номерлы

боерыгы)(«Законность» басмасы, 2009, № 5, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Дәүләт контролен (күзәтчелеген) һәм муниципаль контрольне гамәлгә ашырганда юридик затларның һәм шәхси эшкуарларның хокукларын яклау турында» Федераль закон нигезләмәләрен тормышка ашыру хакында» 2009 елның 30 апрелендәге 141 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы) (Российская газета, 2009, 14 май, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Россия Федерациясе Төбәк үсеше министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларының вәкаләтле башкарма хакимият органнары тарафыннан күпфатирлы йортлар белән идарә итү өлкәсендә эшчәнлекне гамәлгә ашыручы оешмаларның мәгълүмат ачу стандартын үтәвен тикшереп торуны гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2012 елның 9 апрелендәге 162 номерлы боерыгы (Российская газета, 2012, 25 май);

Россия Федерациясе Төбәк үсеше министрлыгының «Россия Федерациясе субъектларында дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру тәртибен, шул исәптән муниципаль торак контроле органнарының Россия Федерациясе субъектларының төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыручы вәкаләтле башкарма хакимият органнары белән хезмәттәшлек итү тәртибен һәм дәүләт торак күзәтчелеге һәм муниципаль торак контроле буенча функцияләр башкаруның административ регламентларын эшләү буенча методик күрсәтмәләр раслау турында» 2013 елның 23 августындагы 360 номерлы боерыгы («Нормирование в строительстве и ЖКХ» басмасы, № 5, 2013);

Россия Федерациясе Генераль прокуратурасының «Җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаи затлар эшчәнлегенә дәүләт контролен (күзәтчелеген) гамәлгә ашыруга вәкаләтле дәүләт органнары тарафыннан тикшерүләр уздыруның еллык планын формалаштыру һәм прокуратура органнарында килештерү тәртибе турында һәм җирле үзидарә органнары һәм җирле үзидарә органнарындагы вазыйфаи затларның эшчәнлегенә планнан тыш тикшерүләрне прокуратура органнарында килештерү тәртибе турында» 2014 елның 21 апрелендәге 222 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Генпрокуратурасының 222 номерлы боерыгы) (Законность, 2014, № 7);

Россия Федерациясе Икътисадый үсеш министрлыгының «Россия Федерациясе территориясендә, Ерак Көнчыгыш федераль округы территориясеннән тыш, оештырылган алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата дәүләт контроле (күзәтчелеге) һәм муниципаль контроль органнар тарафыннан планнан тыш тикшерүләр уздыруны килештерү тәртибен раслау турында» 2016 елның 19 декабрендәге 817 номерлы боерыгы (алга таба – Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгы) (Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2017, 21 март, бастырып чыгару номеры: 0001201703210041);

Татарстан Республикасы Конституциясе;

«Татарстан Республикасында гражданнарның мөрәҗәгатьләре турында» 2003 елның 12 маендагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы законы (алга таба – 16-ТРЗ номерлы закон) (Республика Татарстан, 2014, 2 август, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Гражданнарның торак хокукларын яклауны тәэмин итү турында» 2011 елның 10 октябрендәге 72-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (Республика

Татарстан, 2011, 21 октябрь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

«Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда уртак мөлкәткә капиталь ремонт уздыруны оештыру турында» 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы (алга таба – 52-ТРЗ номерлы Закон) (Республика Татарстан, 2013, 28 июнь, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе мәсьәләләре» 2011 елның 26 декабрендәге 1068 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2012, № 10, 0383 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасы турында» 2013 елның 23 августындагы 593 номерлы карары (алга таба – 593 номерлы ТР Министрлар Кабинеты карары)(«Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2013, № 65, 2059 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне капиталь ремонтлауга минималь кертем күләмен билгеләү турында» 2013 елның 29 июнендәге 450 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2014, № 29, 0846 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «2014-2018 елларга Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләрендә коммуналь хезмәтләргә гражданнар тарафыннан кертелә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индексларын раслау турында» 2014 елның 30 апрелендәге 283 номерлы карары («Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карарлары һәм боерыклары һәм республика башкарма хакимият органнары норматив актлары җыентыгы» журналы, 2014, № 37, 1159 ст., кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген оештыру һәм гамәлгә ашыру тәртибен раслау турында» 2018 елның 28 февралендәге 128 номерлы карары (алга таба – 128 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы PRAVO.TATARSTAN.RU, 2018, 9 апрель, кертелгән үзгәрешләрен исәпкә алып);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында рискка юнәлдерелгән алым кулланыла торган төбәк дәүләт тикшерүе (күзәтчелеге) төрләре исемлеген раслау турында» 2018 елның 27 сентябрендәге 856 номерлы карары (алга таба – 856 номерлы ТР МК карары)(Хокукый мәгълүматның рәсми интернет-порталы (www.pravo.gov.ru), 2018, 3 октябрь);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы территориясендә күпфатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшкуарлык эшчәнлеген лицензияле контрольдә тотуны гамәлгә ашырганда юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар эшчәнлеген куркынычлылыкның билгеле бер категориясенә кертү критерияләрен раслау турында» 2018 елның 31 октябрендәге 971 номерлы карары

(алга таба – 971 номерлы ТР МК карары) (Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталы PRAVO.TATARSTAN.RU, 2018, 26 ноябрь).»;

1.4 пунктта «күпфатирлы йортларда уртак мөлкәтне файдалану һәм карап тоту,» сүзләреннән соң «күпфатирлы йортта бүлмәләрне үзгәртеп планлаштыруны һәм (яки) үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру тәртибенә» сүзләрен өстәргә

1.5 пунктта «шәхси эшкуарларның» сүзләреннән соң «, шул исәптән 473-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентлары булып торучы,» сүзләрен өстәргә;

1.7 пункттагы 11 пунктчага «һәм 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясы» сүзләрен өстәргә;

түбәндәге эчтәлекле 1.9.[1] пунктын өстәргә:

«1.9.[1] Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентына карата урынга чыгып уртак планлы тикшерү уздырылганда анда федераль округ территориясендә, федераль округлар территорияләрендә алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территорияләрен оештыру өлкәсендә Россия Федерациясе Хөкүмәтеннән вәкаләт бирелгән федераль башкарма хакимият органы вәкиле (алга таба – вәкаләтле федераль орган) һәм (яки) алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе идарәче компаниясе вәкиле катнашырга мөмкин.»;

1.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.11. Дәүләт функциясен үтәү нәтиҗәсе булып түбәндәгеләр тора:

1) тикшерү нәтиҗәләре турында, шул исәптән зарури таләпләрнең ачыкланган бозулары турында белешмәләрне үз эченә алган, тикшерү актының Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган үрнәк рәвешенә туры китереп, ике нөсхәдә төзелгән тикшерү акты;

2) тикшерүләрне исәпкә алу журналында (булган очракта) урынга чыгып уздырылган тикшерү турында язу (тикшерүләрне исәпкә алу журналының рәвеше РФ Икътисадый үсеш министрлыгының 141 номерлы боерыгы белән расланган);

3) 294-ФЗ номерлы федераль законның 13.3 статьясы һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 415 номерлы карары нигезендә бердәм тикшерүләр реестрына кертелгән тиешле мәгълүмат;

4) РФ Хөкүмәтенең 482 номерлы карары нигезендә «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт карары» дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат;

5) 593 номерлы ТР МК карары нигезендә «Татарстан Республикасының йогынты ясау актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән тиешле мәгълүмат;

зарури таләпләрнең бозылу очраклары ачыкланганда, шул исәптән административ хокук бозу составы билгеләре булганда:

6) зарури таләпләрнең ачыкланган бозуларын бетерү турында күрсәтмәләр, мондый бозуларны бетерү чорларын билгеләп, ул тикшерү актына кушымта булып тора;

7) административ хокук бозу турында беркетмә (Административ хокук бозулар турында РФ кодексында каралган административ хокук бозу билгеләре

ачыкланганда).

Әгәр тикшерү барышында Инспекциянең вазыйфаи затлары законнардагы таләпләрнең бозылу очракларын ачыкласа, аларны ачыклау, чикләү һәм тыю мәсьәләләре Инспекция компетенциясенә кагылмаса, мондый бозулар турында мәгълүматларны (белешмәләрне) үз эченә алган хатлар Россия Федерациясенең тиешле вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына яисә Татарстан Республикасының вәкаләтле дәүләт хакимияте органнарына җибәрелә.»;

2 бүлектә:

2.4 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«эшчәнлеге 128 номерлы ТР МК карары нигезендә югары һәм шактый куркынычлы категориягә кертелгән күзәтчелек объектлары турында тиешле мәгълүмат.»;

2.10 пунктта түбәндәге эчтәлекле абзацлар өстәргә:

«Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата планлы тикшерү уздыру срогы аны уздыра башлау датасыннан алып иң күбе унбиш эш көне тәшкил итә.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата урынга чыгып планлы тикшерү үткәрүнең гомуми вакыты бер елга кече предприятие өчен кырык сәгатьтән һәм микропредприятие өчен ун сәгатьтән артык була алмый. Тикшерүне уздыручы Инспекция вазыйфаи затларының нигезле тәкъдимнәре нигезендә катлаулы һәм (яки) озак вакытлы махсус тикшеренүләрне һәм экспертизаларны уздыру зарурлыгына бәйле искәрмәле очракларда, тикшерү уздыру срогы озынайтыла, ләкин кече предприятиеләргә карата иң күбе – ун эш көненә һәм микропредприятиеләргә карата иң күбе – ун сәгатькә.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясенең бер резидентына карата планнан тыш тикшерү уздыру срогы биш эш көненнән артык була алмый.»;

2.11 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.11. Төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашырганда куркыныч-юнәлешле якын килүне кулланып планлы тикшерүләр РФ Хөкүмәтенең 806 номерлы карарына, 856 номерлы ТР МК карарына ярашлы рәвештә уздырыла.

Юридик затларга (төбәк операторларыннан гайре), шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр алар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлеккә 128 номерлы ТР МК карары нигезендә беркетелгән куркынычлылык категориясенә карап билгеләнгән ешлык белән уздырыла.

Төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашырганда куркыныч-юнәлешле алымны куллану максатларында юридик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлеге Инспекция башлыгы (башлык урынбасары) карары нигезендә 128 номерлы ТР МК карарында билгеләнгән критерияләргә ярашлы рәвештә билгеле бер куркынычлылык категориясенә кертелергә тиеш.

Юридик затлар, шәхси эшкуарлар тарафыннан гамәлгә ашырыла торган эшчәнлекне билгеле бер куркынычлылык категориясенә кертү турында карар булмаган очракта, юридик затларның, шәхси эшкуарларның эшчәнлеге түбән дәрәҗәдәге куркынычлылык категориясенә кертелгән булып санала.

Юридик зат яки шәхси эшкуар 806 номерлы РФ Хөкүмәте карарында билгеләнгән тәртиптә үз эшчәнлекләренә элегрәк бирелгән куркынычлылык

категориясен үзгәртү турында Инспекциягә гариза бирергә хокуклы.»;

2.12.2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.12.2. Юридик затларга, шәхси эшкуарларга планлы тикшерү билгеләнгән тәртиптә Инспекция тарафыннан эшләнгән һәм расланган юридик затларга, шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр уздыруның еллык планы (алга таба – юридик затларны, шәхси эшкуарларны тикшерүнең еллык планы) нигезендә һәм аңа ярашлы рәвештә уздырыла.

Юридик затларга, шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр, критерияләргә ярашлы рәвештә алар тарафыннан гамәлгә ашырылучы эшчәнлеккә беркетелгән куркынычлылык категориясенә карап, түбәндәге ешлыкта уздырыла:

югары дәрәҗәле куркынычлылык категориясе өчен – елына бер мәртәбәдән артык түгел;

шактый дәрәҗәдәге куркынычлылык категориясе өчен – ике елга бер мәртәбәдән ешрак түгел;

уртача дәрәҗәле куркынычлылык категориясе өчен – өч елга бер мәртәбәдән ешрак түгел;

түбән дәрәҗәдәге куркынычлылык категориясе өчен – дүрт елга бер мәртәбәдән ешрак түгел.»;

2.12 пунктка түбәндәге эчтәлекле 2.12.3 пунктча өстәргә:

«2.12.3. Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларын тикшерүләрнең еллык план проекты Инспекция тарафыннан эшләнә һәм 473-ФЗ номерлы федераль закон, РФ Хөкүмәтенең 1132 номерлы карары нигезендә вәкаләтле федераль органга килештерүгә һәм 294-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә прокуратура органнарына килештерүгә җибәрелә.»;

2.13.2 пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.13.2. Планлы тикшерүне юридик затларга, шәхси эшкуарларга планлы тикшерүләр уздыруның еллык планына кертү өчен планлы тикшерү уздырылган елда юридик затның, шәхси эшкуарның эшчәнлеге карый торган куркынычлылыкның тиешле категориясе өчен билгеләнгән вакыт чорының узуы нигез булып тора, түбәндәге датадан башлап:»;

2.13.3 пунктка түбәндәге эчтәлекле абзац өстәргә:

«2019 елның 1 гыйнварыннан башлап 2020 елның 31 декабренә кадәрге чорда «Россия Федерациясендә кече һәм урта эшкуарлыкны үстерү турында» 2007 елның 24 июлендәге 209-ФЗ номерлы федераль законның 4 статьясындагы нигезләмәләргә ярашлы нигездә кече эшкуарлык субъектларына кертелгән юридик затларга һәм шәхси эшкуарларга карата планлы тикшерүләр 294-ФЗ номерлы федераль законның 26.2 статьясындагы таләпләргә ярашлы рәвештә оештырыла һәм үткәрелә.»;

2.14 пунктның 2.5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

а) түбәндәге таләпләрнең бозылуы:

– күпфатирлы йортларда һәм торак йортларда милекчеләргә һәм биналардан файдаланучыларга коммуналь хезмәтләр күрсәтү, туктатып тору һәм чикләү кагыйдәләре;

– торак милекчеләре ширкәтен, торак, торак-төзелеш яки башка төрле махсуслаштырылган кулланучылар кооперативын төзү тәртибенә, торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яки башка төрле махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы уставы;

– торак милекчеләре ширкәте, торак, торак-төзелеш яки башка төрле махсуслаштырылган кулланучылар кооперативы уставына үзгәрешләр кертү тәртибе;

– күпфатирлы йортта биналарның милекчеләре тарафыннан, идарәче оешма белән күпфатирлы йортка идарә итү шартнамәсен төзү максатларында, күпфатирлы йортка идарә итү эшчәнлеген гамәлгә ашыручы (алга таба – идарәче оешма) юридик затны, оешу-хокук формасына бәйсез рәвештә, яки шәхси эшкуарны сайлау турында карар, идарәче оешма белән күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту һәм ремонтлау буенча хезмәтләр күрсәтүгә һәм (яки) эшләр башкаруга шартнамә төзү турында карар, Россия Федерациясе Торак кодексының 164 статьясының 1 өлешендә күрсәтелгән затлар белән күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләр күрсәтүгә һәм (яки) ремонтлау буенча эшләр башкаруга шартнамәләр төзү турында карар кабул ителү тәртибе;

– күпфатирлы йортта бүлмәләрне үзгәртеп планлаштыруны һәм (яки) үзгәртеп коруны гамәлгә ашыру тәртибе;

– күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту буенча хезмәтләр күрсәтүгә һәм (яки) ремонтлау буенча эшләр башкаруга шартнамәләрнең шартларын раслау тәртибе, күпфатирлы йортта биналарның милекчеләренең уртак мөлкәтен карап тоту һәм әлеге йортта уртак мөлкәтне капиталь ремонтлау тәртибе;

б) идарәче оешманың Россия Федерациясе Торак кодексының 162 статьясының 2 өлешендә каралган бурычларны бозуы;

в) коммуналь хезмәтләр өчен гражданнар кертә торган түләү күләмен үзгәртүнең чик (максималь) индексларын куллану өлкәсендәге бозулар;

г) коммуналь ресурсларны (коммуналь хезмәтләрне) файдалануның билгеләнгән норматив күләменең нигезсез булуы, коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативлары составына карата куелган таләпләрнең бозылуы, коммуналь ресурслардан (коммуналь хезмәтләрдән) файдалану нормативларын билгеләү шартларын һәм методларын сакламау, күпфатирлы йортта уртак мөлкәтне карап тоту кагыйдәләрен һәм торак урынны карап тоткан өчен түләү күләмен үзгәртү кагыйдәләрен бозу;

д) социаль файдаланудагы наем йортларында торак урыннарын наемга тапшыручылар тарафыннан мондый йортларда наемга бирүчеләргә һәм торак урыннарны наемга алучыларга карата, социаль файдаланудагы торак фондына караган торак урыннарының наем шартнамәләрен һәм торак урыннарның наем шартнамәләрен төзүгә карата таләпләрнең бозылуы;»

3 бүлектә:

1 нче таблицаның 6 нчы юлын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «Күпфатирлы йортта бүлмәләрне үзгәртеп кору һәм үзгәртеп планлаштыру тәртибе | Күпфатирлы йортта бүлмәләрне үзгәртеп кору һәм (яисә) үзгәртеп планлаштыру җирле үзидарә органы кабул иткән карар нигезендә аның белән килешү буенча, законнардагы таләпләрне үтәп гамәлгә ашырыла | РФ ТК 4 бүлеге | -» |

5 бүлектә:

түбәндәге эчтәлекле 5.1.[1] пунктын өстәргә:

«5.1.[1] Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына карата төбәк дәүләт торак күзәтчелеге әлеге Регламент нигезендә һәм 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясында, РФ Хөкүмәтенең 1132 номерлы карарында, Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы боерыгында билгеләнгән үзенчәлекләрне исәпкә алып гамәлгә ашырыла.»;

5.6 пунктның беренче, икенче абзацларында «Хокук идарәсе» сүзләрен «контроль-аналитика бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

5.7 пунктның беренче, икенче абзацларында «Хокук идарәсе» сүзләрен «контроль-аналитика бүлеге» сүзләренә алмаштырырга;

5.7 пунктка түбәндәге эчтәлекле 5.7.2 пунктча өстәргә:

«5.7.2. Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларын тикшерүләрнең еллык план проектын әзерләү, аны вәкаләтле федераль орган белән килештерү 473-ФЗ номерлы федераль законның 24 статьясы, Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына дәүләт контролен (күзәтчелеген) муниципаль контрольне гамәлгә ашыруга вәкаләтле органнар тарафыннан уртак планлы тикшерүләр уздыруның РФ Хөкүмәтенең 1132 номерлы карары белән расланган кагыйдәләре нигезендә гамәлгә ашырыла, күрсәтелгән план проектын прокуратура органнары белән килештерү 294-ФЗ номерлы федераль закон нигезендә гамәлгә ашырыла.»;

5.27 пунктның 3 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3) административ процедура нәтиҗәләре турында Тикшерүләрнең бердәм реестрына, «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт карары» дәүләт мәгълүмат системасына, «Татарстан Республикасының йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән мәгълүматлар.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.34.[1] пунктын өстәргә:

«5.34.[1] Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларына планнан тыш тикшерүләр вәкаләтле федераль орган белән килешү буенча Россия Икътисадый үсеш министрлыгының 817 номерлы карарында билгеләнгән тәртиптә уздырыла.»;

5.59 пунктның бишенче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«– административ процедура нәтиҗәләре турында Тикшерүләрнең бердәм реестрына, «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт карары» дәүләт мәгълүмат системасына, «Татарстан Республикасының йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән мәгълүматлар.»;

түбәндәге эчтәлекле 5.67.[1] пунктын өстәргә:

«5.67.[1] Планлы тикшерү уздырылган вакытта алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентының Россия Федерациясе законнарын бозуы ачыкланганда, Инспекциянең вазыйфаи затлары алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентына бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирә. Бозуларны бетерү турында күрсәтмә күчермәсе планлы тикшерү уздыру нәтиҗәләре турында акт төзелгән датадан башлап өч көн узмаган чорда алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентына яки аның вәкиленә кул куйдыртып тапшырыла яки мондый күрсәтмәнең алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты яки аның вәкиле тарафыннан алынуын таныклый торган башка төрле ысул белән тапшырыла. Әгәр күрсәтелгән ысуллар белән бозуларны бетерү турында күрсәтмәне алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентына яки аның вәкиленә тапшыру ихтималы булмаса, ул почта аша заказлы хат итеп җибәрелә һәм аны җибәргән датадан соң алты көн узгач алынган дип санала.

Инспекция алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентына планнан тыш тикшерүне бозуларны бетерү турында күрсәтмә бирелгән датадан соң ике ай узгач уздыра. Әгәр бозуларны бетерү өчен ике айдан артыграк вакыт таләп ителсә, планнан тыш тикшерү бозуларны бетерү турында күрсәтмәдә билгеләнгән срокларда, ләкин мондый күрсәтмә чыгарылган датадан алып алты ай узганчы үткәрелә.

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты планнан тыш тикшерү уздырылганчыга кадәр бозуларын бетерү турында күрсәтмәне үтәмәгән очракта, эшчәнлекне гамәлгә ашыру турында килешү өзелергә һәм алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резиденты статусы вәкаләтле федераль органның гаризасы нигезендә суд карары нигезендә туктатылырга мөмкин.

5.96 пунктның 5 пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5) административ процедура нәтиҗәләре турында Тикшерүләрнең бердәм реестрына, ТФМ ДМС, «Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча бертип болыт карары» дәүләт мәгълүмат системасына, «Татарстан Республикасының йогынты актларының җыелма реестры» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасына кертелгән мәгълүматлар.»;

Регламентка 2 нче кушымтаны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан Татарстан Республикасында төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен үтәүнең административ регламентына 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Дәүләт торак инспекциясе тарафыннан төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру буенча дәүләт функциясен башкаруга
БЛОК-СХЕМА

Төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашыру

Торак фонды объектларын карау (тикшерү, тикшереп чыгу), шул исәптән тикшерелә торган затлар белән бәйләнешкә кермичә

Срогы – 15 көн

Зарури таләпләр үтәлешенә системалы рәвештә күзәтү, төбәк дәүләт торак күзәтчелеген гамәлгә ашырганда зарури таләпләрне үтәү торышына анализ һәм фараз

Срогы – даими

Тикшерүләрнең еллык планын әзерләү

Срогы – 3.5 ай

Планнан тыш тикшерү уздыруны оештыру

Срогы – 3 эш көне

Планлы тикшерү уздыруны оештыру

Срогы – 5 эш көне

Планнан тыш тикшерү уздыру

Срогы – 20 эш көне

Алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентына карата – 5 эш көненнән артык була алмый

Планлы тикшерү уздыру

Срогы – 20 эш көне, кече эшкуарлыкның бер субъектына карата планлы урынга чыгып тикшерү уздыру срогы – елына 50 сәгатьтән артык түгел.

Микропредприятие өчен планлы урынга чыгып тикшерү уздыру срогы – елына 15 сәгатьтән артык түгел;

алгарышлы социаль-икътисадый үсеш территориясе резидентларын тикшерү – аны уздыра башлаган датадан алып 15 эш көненнән артык түгел.
Кече эшкуарлык субъекты булып торучы бер резидентка карата – кече предприятие өчен елына 40 сәгатьтән һәм микропредприятие өчен елына 10 сәгатьтән артык була алмый.
Искәрмәле очракларда тикшерү уздыру срогы озынайтыла, кече предприятиеләргә карата 10 эш көненнән артык түгел һәм микропредприятиеләргә карата 10 сәгатьтән артык түгел

Тикшерү уздырылганда ачыкланган бозу фактларына карата чаралар күрү
Срогы – 1 эш көне

».

2. Юридик бүлек башлыгына (Н.Н. Воронская) әлеге боерыкны дәүләт теркәвенә алу өчен Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгына җибәрергә.

3. Әлеге боерык үтәлешен тикшерүдә тотуны башлык урынбасары – хокук идарәсе башлыгы В.С. Саттаровка йөкләргә.

Башлык С.А. Крайнов